# TATAR ŞİİRİNDE SÜYÜMBİKE VE SÜYÜMBİKE MİNARESİ TEMALARI*

**Yard. Doç. Dr. Çulpan ZARİPOVA ÇETİN**

Muğla Üniversitesi Fen-Edebiyat Fakültesi
Çağdaş Türk Lehçeleri ve Edebiyatları Bölümü

## ТАТАР ШИГЫРЕНДӘ СӨЕМБИКӘ ҺӘМ СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ ОБРАЗЛАРЫ

Фаҗигале тарихның телсез шаҺиде Сөембикә манарасы бары тик Татарларның башкаласы Казан шәҺәренең генә түгел, ә бәлки бөтен татар миллэтенең күркәм символына әйләнде. Казанны Сөембикә манарасыннан башка күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, бу манараны күрмәгән яисә ишетмәгән, ә инде ишетеп тә күрергә теләмәгән татар кешесен дә табу кыендыр, мөгаен.

Казан шәһәренең йөзек ташы булып саналган Сөембикә манарасы менә инде ничә гасырлар буе Ак Кремльнең нәкъ уртасында, Казанның иң биек ноктасында Казансу елгасы буенда күккә очынган мәгърур бер халәттә басып тора... Аны татар шагыйрьләре бала итәкле милли күлмәк кигән алсу йөзле, зифа буйлы һәм тыныч холкы белән күргәннәрне хәйран иткән татар кызына охшаттылар һәм бу очраклы түгел әлбәттә: манара, Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә исемен йөртә.

Ногай мирзасы Йосыфның кызы Сөембикә, мәгълум булганча, соңгы өч Казан ханына (Җангали, Сәфәгәрәй Һәм ШаҺгалигә) хатын булып торган, гүзәллеге Һәм акылы белән дан тоткан. Ләкин ханбикәнең язмышы, кызганыч, үзе кадәр матур булмаган... Сөембикә, татарларның йөрәгендә Һәм хәтерендә гасырлар буе моңлы бер җыр булып яшәргә дәвам итә...

Сөембикәнең шәхесе Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, аеруча соңгы дәверләрдә татар тарихында аның исемен йөрткән манара белән бербөтен булып карала башлый. Татарлар, тол калып, сабый бала белән бергә әсир җибәрелгән, ә инде соңыннан баласыннан аерылып чит-ят җирдә җан биргән һәм төгәл генә кабере дә билгеле булмаган ханбикәне милләт анасы дәрәҗәсенә күтәреп, аның аянычлы язмышының эзләрен ватанында калган бердәнбер истәлектән – Сөембикә манарасыннан эзләргә тырыштылар.

Татар шигырендә Сөембикә ханбикәнең язмышын манара белән бербөтен итеп карау XX йөз башында күзәтелә башлый Һәм моның иң матур үрнәге – Мәҗит Гафуринең «Сөембикә манарасы» исемле шигыредер, мөгаен. Бу шигырьдә манара нәкъ менә Сөембикәнең үзе кебек аянычлы язмышына һәм дәүләтенең, халкының яшәгән фаҗигасенә сызланып, күз яшьләре түгә... Һәм игътибар итсәк, ул бу хәлләргә кычкырып түгел, ә нәк менә татар хатыннары кебек, сүзсез генә, бер кешегә дә белдермичә, ләкин бу күз яшьләренә шаһит булганнарны тетрәндерә торган итеп елый:

> “...Мин беләм белдермәсәң дә: агадыр күздән яшең,
> Бу хәлеңнән шикаять кылды синең һәрбер ташың, -
> Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.” -

---

* Bu makale Tatar Türkçesi’nde yazılmış olup, “**Süyümbike-Hanbike.** Tarihi, Fenni hezmetler, beyanlar, edebi eserler, eserlerden özekler.” adlı kitapta yayınlanmıştır (Kazan, 2006.s. 176–180.)

дип языла шигырьдә... Манара (ә ул шагыйрь тарафыннан Хан мәсҗеде дип искә алына) бу шигырьдә әйтерсең лә Сөембикә үзе: Кремль эчендә, җимерелгән мәчетләрнең ташыннан салынган чиркәүләр арасында калган манара, әсир итеп алынганнан соң руслар арасында ялгыз башына яшәргә мәҗбүр булган Сөембикәне хәтерләтә түгелме безгә:

> “Һәб кәлисә уртасында ялгызың калдың ничөн?”

Ул бу хәле белән бары тик аерым кешеләрне, бары тик үз милләтен генә түгел, ә бәлки бөтен ислам дөньясын, бөтен мәселманнарны хәсрәт утына сала:

> “Әһле ислам кальбенә син хәсрәтне салдың ничөн?”

Ләкин алай гына да түгел. Сөембикә манарасы әле тагын бик күп гасырлар буе безгә дүрт гасыр элек Казан ханлыгының урыслар тарафыннан алынуын гына түгел, ә бәлки үз милләтебез эчендәге битарафлылык белән хыянәтне дә хәтерләтеп торачак... Мәҗит Гафуринең бу шигырендә манара хаклы рәвештә нәк менә әле Казан алынганчы ук урыслар кулына әсир итеп тапшырылган Сөембикә кебек рәнҗеп, үз милләтеннән өметен өзгән вазгыяттә тасвир ителгән:

> “Илтифатың без татардан син, бина, алдың ничөн?”
>
> “Син өмид өзсәң дә бездән – без өметне өзмәдек”...

кебек шигъри юллар моңа дәлил булып тора.

Әйе, манара биредә җанлы: ул тавышсыз гына елый, ул дошманнар арасында япа-ялгыз калган, ул рәнҗетелгән, өметен өзгән... Ләкин ул нәкъ менә бөтен кешеләргә хас булганча, бәлки Сөембикәнең үзе кебек, тормышының иң авыр, иң фаҗигале минутларында элекке шатлык һәм өмет белән тулы ямьле көннәрен, елларын искә ала... Бу шигырьдә вакыт әйтерсең лә икегә бүленеп бирелә: бер якта - фаҗигале чынбарлык, икенче якта - үткәндә калган дәүләтле-тәхетле язлар, милли һәм дини байраклар югарыда, биектә очынып торган шәүкәтле көннәр:

> “Бер заманлар синдә намаз укыганнар хан иде,
> Кауме татар һәм төрекнең мәскәне Казан иде.
> Ул вакытны тасвир итсәк, ни гүзәл заман иде!”
>
> “Бер вакытлар синдә торды әһле ислам гаскәре.”

Ләкин бу матур хәтирәләр, татлы уйланулардан соң янә гаҗизлек эчендәге чынбарлыкка, Казан ханлыгы алынганнан соңгы дансыз-шансыз, ислам байрагы тапталган, дошманнар хөкемсергән көннәргә кайта хәтер:

> “Шәүкәтең бетте бүгендә, калмады меңнән бере,
> Башкаларның йире булды ошбу көн ислам йире”.

Шагыйрь бу шигырендә чарасызлыктан сызланып, үткәндә ясалган хаталар өчен ул дәвердә сүзсез, битараф калып, соңырак чорларда моны яшәү рәвеше итеп алган халкы, милләте өчен Сөембикә ханбикәдән гафу үтенә кебек...

“Син өмид өзсәң дә бездән – без өмидне өзмәдек,
Заһирән түзсәк тә безләр – кальбемездән түзмәдек.
Җаһил улган бер заманда кыйммәтеңне белмәдек,
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.”

Мәҗит Гафури бу шигырендә манара мисалында Сөембикә ханбикә язмышының фаҗигалелеген шул кадәр оста итеп ачып биргән ки, Сөембикәнең кичерешләре белән шагыйрь күңлендә яткан моң, тетрәнү, кайгы бербөтен булып үрелеп бара.

Халык шагыйре Ильдар Юзиевнең “Сөембикә манарасы янында” исемле шигыре дә Мәҗит Гафуриның “Сөембикә манарасы” исемле шигыренә аваздаш булып тора. Ул да манара янында милләт язмышы турында уйлана һәм татар тарихының канлы сәхифәләрен үз күңеленнән үткәреп, киләчәккә өмет белән карарга тырыша. Ләкин биредә шагыйрьне шигырь язарга этәргән деталь башка. Ул - Сөембикә ханбикәнең фаҗигале язмышының символы булып торган манараның авыша башлавы. Мәгълум булганча, манара, нигезе тигез утырмавы сәбәпле, акрынлап көнчыгыш тарафка авыша. Ләкин Ильдар Юзиев милләтпәрвәр һәм шагыйрь буларак моның төп сәбәбен янә XVI гасырдагы давыллы вакыйгалардан эзли:

“Тарих серенә төшәргә
Омтылган бораy кебек,
Хәлсезләнеп башын игән
Авыр бер сорау кебек.”

Сөембикә манарасы Советлар чорында айсыз иде һәм бу авыр хәлгә татар шагыйрьләре битараф калмады. Мәсәлән, Рәдиф Гаташ та Сөембикәгә багышланган озын шигырендә манараның башындагы айны Сөембикә ханбикәнең башындагы таҗга охшатып болай язды:

Сөембикә, манараңа
Ай кунар бит тагын?
Кабат кайтыр таҗың..

Биредә ханбикәнең башыннан таҗы төшүе белән манарадан айның алынуы арасында бер параллель үткәрелә: айсыз манара таҗсыз ханбикәне хәтерләтә... Ләкин шагыйрь ышана: киләчәктә хакыйкать барыбер өстен чыгачак, татар милләте асылына кайтачак:

Авып, син иңрисең җанда!
Узып бара тагын
Битараф бер гасыр... Күк тә
Дәшми бүген, салкын...
Казан күге! Ә бит синдә
Күпме аһ, моң, ялкын...
Уятачак алар безне,
Тетрәтәчәк, халкым!

Сөембикә манарасы башына ай сиксән елга якын вакыт үткәннән соң ниһаять яңадан куелды... (бу вакыйга үткән гасырның 90 нчы елының Хәтер көненә туры килә). И.Юзиевнең югарыда әйтеп үткән шигырендә манараның авышу сәбәбе аның озак еллар айсыз-имансыз калуына бәйләп каралуы да аңлашыла кебек:

“Узганнарга тарта уйны
Тансык азан тавышы.
Тынгылык бирми күңелгә
Манараның авышы.
Янтайганмы күпме еллар
Иманы-нуры юкка?
Барсына да шаһит бит ул:
Хыянәт, тугрылыкка...”

Ләкин бу шигырьдә шагыйрь әйтергә теләвенчә, Сөембикә манарасыннан бигрәк, татарның тарихы авышкан, миһербансызлыктан, битарафлылыктан, телене, динене, денене югалтудан кешеләрнең күңеле авышкан... Ильдар Юзиевне борчыган сорау барыбызның да үзәгендә: бу хәтле шанлы, дәүләтле тарихы булган татар халкы көннәрдән бер көн үзе дә манара кебек аумасмы, тарих тузанына күмелеп югалмасмы? Милләт үзендә үткәннәрне барлап, кирәкле нәтиҗәләр ясап яңарырлык көч таба алырмы? Яшәрме?..

“Шәһитләрнең кан-яшьләре
Өстебезгә аумасмы?
Манарабыз турыланыр,
Милләт үзе аумасмы?”

XX йөзьел һәм көнебез татар шигырендә Сөембикә образына багышланган шигырьләрдә Сөембикә манарасы белән бәйле риваятьләр дә урын ала башлый. Алар арасында иң мәшһүре – Явыз Иванның Сөембикәнең матурлыгы турында ишетеп, Казанга илчеләр җибәрүе белән бәйле. Бу риваятькә күрә, Явыз Иван Сөембикә ханбикәгә Мәскәү патшасының хатыны булырга тәкъдим ясый. Әмма горур Сөембикә кискен төстә баш тарта. Гарьлегенә түзә алмыйча, патша зур гаскәр туплап Казанга һөҗүм итә һәм шәһәрне камап ала. Җиде ел камап торганнан соң, кирмән диварларын ваттырып Казанны ала. Бу хәлне күреп Сөембикә ханбикә Явыз Иванга кияүгә чыгарга ризалык бирә, ләкин бер шарт куя: туй бүләге итеп рус патшасы җиде көн эчендә Казанда биеклегенә һәм гүзәллегенә тиңе булмаган манара салырга тиеш. Җиде көн дигәндә манара салынып бетә. Сөембикә яшәгән шәһәре һәм халкы белән хушлашу өчен манараның иң югары катына чыгарга рөхсәт сорый. Ләкин менеп җиткәч, кайгысын күтәрә алмыйча, түбәнгә ташлана... Башка бер риваятьтә исә “Сөембикә дошманның җиңүен күргәч, ире күмелгән мәчетнең манарасына менә дә аска ташлана” диелә. Күргәнебезчә, риваятьләрнең һәр икесендә дә Сөембикә дошман кулында әсир булудан үз шәһәрендә ирекле булып үлүне өстенрәк күрә... Риваятҗләргә күрә, менә шул көннән бирле бу манара Сөембикә исеме белән телгә алына башлый да инде.

«Шагыйрәнә ялган» булган бу риваять шагыйрьләргә озак еллар дәвамында илһам чыганагы булып торды. Сөембикәнең чынлыктагы кебек әсир китүе түгел, ә бәлки газиз халкын, ватанын ташлап китүне күтәрә алмыйча манарадан сикерүе шагыйрь күңелен үзенең фаҗигалелеге, фидаилеге белән тетрәтте. Гамил Афзал бу риваятькә таянып “Сөембикә-сылу” исемле агымсу кебек йөгерек легенда иҗат итте. Бу легенда Казан ханлыгын мәгрифәт үзәге итеп җитештереп, халкын кайгыртып яшәгән тол ханбикәнең дәүләтендә шомлы көннәр кичерүе белән башлана:

“Күлмәкләрең ефәк,
Камзулларың бәрхет,
Җаныңа юк тынгы,

Үзеңә юк бәхет.
Илем, диеп ела,
Илем, диеп көен,
Хәлең авыр синең,
Сөембикә килен.”

Үз биләре тарафыннан Мәскәүгә әсир җибәреләчәге турында хәбәр алган Сөембикә манарадан сикереп үлүне әсир китүдән өстенрәк күрә:

“Манараңнан кара –
Казан әйләнәсен,
Һай, манараң биек,
Башың әйләнмәсен!
Әҗәл кайгы кебек,
Әҗәл бәхет кебек,
Дала киң булса да,
Дөнья ләхет кебек.
Кәфен төсле итеп
Ак күлмәгең кимә.
Бәхил сүзе ачы,
Бәхил булың, димә.
Һай, манараң очлы,
Һай, манараң биек!..
Ак күгәрчен очты:
“Бәхил... бәхил...” – диеп.”

Ләкин Сөембикәнең манарадан атылуы турындагы “шагыйрәнә ялганга” каршы чыгучы шагыйрьләр дә булды. Нидән? Бер яктан татар милләте, галим Ф.Урманче язуынча, “үзенең хыялында сөекле Сөембикәсен, коточкыч һәлакәткә дучар итеп булса да, урыс патшасына тоткынлыкка эләгүдән “коткарып кала...”[1]. Ләкин икенче яктан, тарихи чынбарлыкны белсә дә, татар халкы Сөембикәне әсирлектә һәлак булган яисә риваятьләрдәге кебек манарадан атылган ханбикә итеп түгел, ә бәлки җиңелмәгән, йөрәкләрдә мәңге исән булып калган һәм әле дә миллионлаган милләттәшен көрәш юлына чакырып торган милләт анасы итеп күзаллый. Розалина Шаһиеваның шигырен моңа иң гүзәл үрнәк дип күрсәтеп була:

“Нәүмиз хатын Сөембикә,
Тол калмаган тоткынлыкта,
Тез чүкмәгән читенлектә,
Кол булмаган тар читлектә,
Атылмаган манарадан, убылмаган биеклектән –
Исән икән, илдә икән,
Тере чыккан хәрабәдән
Сөем-сөем-Сөембикә...
Милли-милли-миллионнар
Азатлык! дип ураганда
Биналарны, мәйданнарны...
Кагынадыр канатларың

[1] Ф.Урманче. Татар халык иҗаты. Казан, “Мәгариф”, 2005, б. 265.

Каурый болыт – Сөембикә.

Розалина Шаһиева да М.Гафури, И.Юзиев кебек Сөембикә манарасын кан белән язылган татар тарихының җансыз шаһиде, татар мөһәҗирлегенең башы буларак кабул итә: татарның фаҗигасе Сөембикә ханбикә фаҗигасе белән бер үк тарихта башлана!

“Мәңге кара яра сыман
Җиде катлы бу манара –
Ниләр күрдең шул арада?
Хәсрәт икән, хиҗрәт икән,
Мәңге тере миһраҗ икән,
Ил өстеннән ыңгырашып
Искән каты җилләр икән,
Ташкын-ташкын мөһәҗирләр
Үткән ачы юллар икән,
Ачылмас гөл, уллар киткән.
Төпсез упкын, дәрья икән
Сөем-сөем-Сөембикә...”

Шагыйрь Зөлфәт исә бераздан аерым карап үтеләчәк “Сөембикәнең хушлашу догасы” исемле шигырендә Сөембикәнең манарадан ташлануын тагын да үзенчәлекле хәл итә:

“Ташланмадым текә, биек манарадан –
Очты манарадан, халкым, синең даның.”

Татар шигъриятендә Сөембикә ханбикәнең монологы рәвешендә язылган шигырьләр дә бар. Аларда инде манара телгә алынмый. Аларда - Сөембикәнең рухи кичерешләре бирелә. Бу уңайдан Мәҗит Гафуриның Сөембикә ханбикәгә багышлап язылган тагын бер шигырен искә алып үтик. Бу шигырь Советлар дәверендә игътибарга алынмый килде, чөнки ул татар халкының милли тарихына, милли каһарманына багышланган. Укучыга беренче мәртәбә 1910 елда тәкъдим ителгән “Сөембикәнең актык көне” исемле шигырь-монолог ханбикәнең үз авызыннан язмышының бу кадәр кара булуына, халкының бу кадәр бәхетсез булуына ачынып, борчылып сөйләнелгән бер мөнәҗәткә охшый:

“Аһ, бу көннәр килде башка, соң минем тәхтем кая?
Хан илә ханым булып торгандагы бәхтем кая?
Дөньяда безгә галиб дошман булыр дип уйламый,
Бездә куәт, бездә шәүкәтләр, дигән вактым кая?
Мин халык өчен көям, шулар өчен дә яшь түгәм,
Бу Казаннан башка җирдә мин табалмам бер дә ямь;
Мин үзем чен түкмәем яшь, бәлки бу казанлылар
Мәңге коллыкта калырлар дип – шуңа хәсрәтләнәм.”

Сөембикәнең Казандан әсир киткән вакытта халкына әйтергә теләп тә күңелендә безнең өчен инде мәңгелек сер булып калган хис-тойгыларына төшенергә теләүче шагыйрьләр соңгы чорда да аз булмады. Мәсәлән, Г.Зәйнашева, Зөлфәт шигырьләрен мисал итеп китереп булыр иде. Шагыйрь Зөлфәтнең “Сөембикәнең хушлашу догасы” исемле шигырендә ханбикәнең соңгы сүзләре шагыйрь тарафыннан “дога” дип аталса

да, аларда Сөембикәнең халкына әйтергә теләгән үпкә, рәнҗеш тә яңгырый кебек. Ул халкына бөтен ачы хакыйкатьне битенә бәреп әйтерлек көч таба. Әйтерсең лә казанлылар каршында чарасыз, нечкә күңелле, йомшак табигатьле хатын-кыз, шәфкатьле ана түгел дә, гайрәт ташып торган, үз артыннан исәпсез халкын көрәшкә күтәрерлек ихтияр көченә ия булган кодрәтле, көчле дәүләт ире, хан басып тора. Биредә әһәмиятле булган тагын бер деталь - Сөембикә үзен, үзенең язмышын халкыннан аерып карый алмый. Ул – үзен яклый алмаган, ханбикәсен әсир җибәргән милләтенең йөз аклыгы гына түгел, аның  тапталган шөһрәте, даны һәм гасырлар буе сызлаячак вөҗданы да әле:

“Алып китә алар мине түгел, халкым,
Китә алар синең шөһрәтеңне төяп!”

“Калаң нигезенә эт күмелгән шәһәр!”

Ләкин шул ук вакытта Сөембикәнең йөрәге, үлем түшәгендә ятканда янында басып торган баласының игелексез булуына карамастан аны барыбер яратырга дәвам иткән ана йөрәге кебек, йомшый төшә һәм ул халкы белән бәхилләшеп, аның урынына аннан үзе гафу үтенә һәм аның язмышы өчен борчылып, инде аны беркайчан да яклап кала алмаячагына ачына:

“Хуш, бәхетсез халкым! Мин калдырам сине
Алларыңда торган мең афәтле килеш,
Киләчәксез килеш мин калдырам сине,
Йөзең канлы килеш, җәрәхәтле килеш...”

“Кичерә күр, халкым! Сау гына бул, халкым!
Тәхетең дә китте, бәхетең дә бетте...”

Зөлфәтнең бу шигыренә тематик яктан якын торган тагын бер шигырь – татар милли азатлык көрәшенең алгы сафында барган Фәүзия Бәйрәмованың “Сөембикә каргышы” дип аталган шигыре. Шагыйрә татар халкының кара язмышка тап булуының сәбәбен янә бер вакытлар Сөембикәгә каршы күрсәтелгән хаксызлыктан, хәтта аның рәнҗешеннән эзли:

”Син каргадың мәллә, Сөембикә,
Бу милләтнең диеп, тамыры чересен!
Аяк-кулың бәйләп Мәскәүләргә
Әсир итеп биргәннәре өчен,
Бу милләтне син каргадыңмы әллә?”

“Илсез, җирсез, телсез калсын, диеп,
Син еладыңмы әллә, салга ятып?”

“Синең рәнҗеш дүрт гасырдан артык
Утлы ярда булып җанда янды.
Каргышларың арттан куа барды...”

Ф.Бәйрәмова да бу шигырендә нәкъ менә башка татар шагыйрьләре кебек татарларны тараткан, аягын-кулын бәйләгән дошманны читтән, урыс дәүләтеннән

эзләми. Шагыйрәнең күңелен борчыган маңкортлык темасы Сөембикә дәвере контекстында, Сөембикә язмышында кара тап булган Шаһгали образы аша ачыла һәм ул татар халкының бүгене белән үрелеп бирелә:

“Шаһгалиләр һаман туа тора,
Азатлыкка юлны буа тора.
Татар түрәләре түргә үрли
Берсен-берсе ярсып этә-тертә,
Ак шәлләргә аяк сөртә-сөртә,
Ак җаннарга аяк сөртә-сөртә...”

Шагыйрә, үз язмышы мисалында, үзе дә яклаучысы булмаган бер хатын-кыз буларак бөтен җаны-тәне белән яхшы аңлый:

“Ханбикәсен корбан итеп биргән,
Хатын-кызны мәйданнарда изгән
Милләт беркайчан да мантый алмас.
Үз дәүләтен халык саклый алмас,
Бәйсезлеген ирләр яклый алмас
Түбәсендә каргыш торганда,
Хатын-кызлар корбан булганда...”

Мисаллардан да аңлашыла кебек: чордаш татар шагыйрьләре тарафыннан язылган шигырьләрдә Сөембикә Һәм Сөембикә манарасы образлары табигый рәвештә татар милли хәрәкәте үсеше белән тыгыз үрелеп бара. Һәм бу табигый да. Сөембикә йөзендә татар халкы үзенең югалткан телен, онытылган тарихын, мәсхәрәләнгән динен, югалткан илен, бәйсезлеген сагына... Ләкин, Равил Фәйзуллинның “Казан алды” исемле шигырендә дә язылганча, инде менә ничә гасырлар буе йокымсырап килгән халык эченнән нихаять телен, динен, киләчәген яклый белүчәк яңа буын, яңа нәсел үсеп чыкты:

“Тེге чакта, Казан аугач,
Дошман әйткәндер: “Бетте!..”
...Таш ярыр гөлләр шикелле
яшь буын үсеп чыгасын
шәһитләр белми китте...”

Мөдәррис Әгъләмнең Казан ханлыгында булып үткән вакыйгаларны бүгенгә ялгап язылган һәм Сөембикәгә иркәләп:

“Сөембикә, кызым, сеңлем, апам,
Әнкәм, әбкәм...”

диеп эндәшкән “Син дә әкиятмени?” исемле шигырендә татар милләтенең бәйсезлеге хаклы рәвештә шик астына куелса да:

“Без каядыр бармак булган идек,
Азат булмак булган идек әле...
Алла бәндәләре булмак булдык,
Ә һаман да Мәскәү бәндәләре...”,

татар милләтенең киләчәгенә өмет белән карыйсы килә. Эчтән ниндидер бер хис, сиземләү “Юк! Бу милләт югалмаячак, бу милләт яшәячәк!” ди... Хәер, Мөдәррис Әгъләм үзе дә белә түгелме бу хакта?

...Күпме куерса да вакыйгалар
Җирдә әле – Иман,
Күктә Ай бар!

Сөембикә - ул безнең үткәнебез дә, бүгенебез дә, киләчәгебез дә. Инде югарыда язып үтелгәнчә, ул безнең йөз аклыгыбыз да, гасырлар буе сызлаячак вөҗданыбыз да. Бәлки дә шуңа күрәдер, аның кабере иленнән еракта, чит җирдә югалып калса да, безнең һәрберебезнең күңелендә Сөембикәне сыйдырачак кадәр урын һәм җан җылысы бар. Татар халкы, татар хәтере яши икән, димәк Сөембикә дә онытылмаячак. Аның исеме белән аталган манара да алты кыйтгада яшәгән татар милләте өчен рухи кыйбла булып яшәргә дәвам итәчәк һәм аның янына гыйбадәт кылырга, Коръән укырга йөрүчеләр һич тә азалмаячак. Ә инде татар милләтенең тарихында фаҗигалелеге белән аерым урын алып торган Казан ханлыгының алыну вакыйгаларын һәм соңгы ханбикәбез Сөембикәнең аянычлы язмышын яңадан телгә алып, чын милли эчтәлекле шигырьләр иҗат итүче чордаш татар шагыйрьләре безне генә түгел, киләчәк буыннарны да тарихтан гыйбрәт алырга чакыра.

Бу мәкаләмне шагыйрь Рәзил Вәлиев шигыре белән тамамлыйсым килә:

Казаныма төннәр иңсә,
Сине эзләп карыйм күккә.
Зәңгәр күктә ай моңлана,
Моңлана күк Сөембикә.

Сине уйлап үтә язлар,
Сине уйлап көзләр җитә.
Яңгыр булып көз еламый,
Син елыйсың, Сөембикә.

Сагышларны сүтә-сүтә,
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.

Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып,
Кайтчы, зинһар, Сөембикә!